СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЯЖЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2020 с. Лебяжье № 149

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм**
**өстәмәләр кертү турында**

Авыл җирлеге башлыгы рәислек итүче докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Лебяжье авыл җирлеге советы, гамәлдәге кануннарның үзгәрүенә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнгәнен билгеләп үтә, ул җирлек Советы тарафыннан хупланган, халык алдында тыңлауларда район халкы белән сөйләшүнең барлык кирәкле процедураларын үткән һәм узган.

Проект район халкы белән фикер алышу барышында килгән гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләнде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 08 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 86-88 маддәләре нигезендә

**Лебяжье авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Советының 2020 елның 18 июнь 101 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә (Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2016 елның 04 март 28 номерлы Лебяжье авыл җирлеге Советы карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының

2016 елның 14 декабрь 48 номерлы Лебяжье авыл җирлеге Советы карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2017 елның 18 декабря 81 номерлы Лебяжье авыл җирлеге Советы карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2018 елның 21 сентябрь 98 номерлы Лебяжье авыл җирлеге Советы карары, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының 2019 елның 25 ноябрь 138 номерлы Лебяжье авыл җирлеге Советы карары ярдәмендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәреш һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Уставының 71 маддәсе нигезендә әлеге карар текстын, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авылы, Үзәк урам, 27А йорт адресы буенча урнашкан Лебяжье авыл җирлеге советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 нче өлеше, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге Уставының 88 маддәсендәге 2 нче өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге Советы Рәисе** **Ю.Л.Белов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районының
Лебяжье авыл җирлеге Советының
2020 елның 30 март
149 номерлы карарына
Кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебяжье авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1). 6 нчы маддәдә:**

20 пунктчаның 1 пунктында түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«20) үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылманы җимерү яисә аны федераль законнарда билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән параметрларына, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү»;

**2). 30 нчы маддәдә:**

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланган 10 депутаттан тора»;

**3). 31 нче маддәдә:**

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-

төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) катнашу, Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына алдан хәбәр итеп;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тапшыру;

г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә авыл җирлеге булган оешманы гамәлгә куючы (катнашучы) булып торучы (акционер) җирлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен җирлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучы, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылар, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә аларның структур бүлекчәләре составына керергә.»;

**4). 49 нчы маддәдә:**

1 пунктның 4 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарга күчерү турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә, торак урыннарны яңадан урнаштыруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, муниципаль һәм хосусый торак фондының торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз, дип таный, Россия Федерациясе яки Татарстан Республикасы милкендә булган, авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш».

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебяжье авыл җирлеге Советы Рәисе** **Ю.Л.Белов**

СОВЕТ ЛЕБЯЖИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ